**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**

**ЧИРМЕШӘН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ**

**КУТӘМӘ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ**

**КАРАР**

**№ 82** **15 ноябрь 2013 ел**.

**Җир салымы турында**

**1. Статья. Гомуми нигезләмәләр**

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 нче бүлеге нигезендә, әлеге карар белән Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районының Кутәмә авыл җирлеге территориясендә мәҗбүри түләү өчен җир салымы билгеләнә һәм гамәлгә кертелә.

**2. Статья. Салым ставкалары.**

Салым ставкалары кадастр бәясеннән түбәндәге күләмдә билгеләнә:

1) авыл хуҗалыгы билгеләнешендәге җирләргә яисә җирлекләрдә авыл хуҗалыгы кулланышы зоналары составындагы җир кишәрлекләренә карата 0,3 % ;

2) торак фонды һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектлары биләгән җир кишәрлекләренә карата (торак фондына һәм торак-коммуналь комплексның инженерлык инфраструктурасы объектларына туры килми торган җир кишәрлегенә хокукындагы өлештән тыш) яки торак төзелеше өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 % ;

3) Россия Федерациясе законнары нигезендә әйләнештә чикләнгән, оборона, куркынычсызлык һәм таможня ихтыяҗларын тәэмин итү өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата 0,3 % ;

4) шәхси ярдәмче хуҗалык, бакчачылык, яшелчәчелек яки терлекчелек һәм шәхси торак төзелеше өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 0,15 % ;

5) җитештерү һәм административ биналарны, төзелмәләрне, сәнәгать, коммуналь хуҗалык корылмаларын урнаштыру, матди - техник, азык-төлек белән тәэмин итү, сату һәм әзерләү өчен билгеләнгән җир кишәрлекләренә карата 1% ;

6) башка җир кишәрлекләренә карата 1,5%.

**3. Статья. Салым ташламалары**

**Салымнардан азат итү**:

1) Бөек Ватан сугышында катнашучыларга, шулай ук Бөек Ватан сугышында катнашучыларның социаль гарантияләре һәм ташламалары законнар белән каралган гражданнарга, шәхси ярдәмче хуҗалык алып бару, шәхси торак төзелеше, бакчачылык, яшелчәчелек һәм терлекчелек алып бару өчен бирелгән җир кишәрлекләренә карата;

2) граждан күмелгән җир кишәрлекләренә карата оешмалар һәм учреждениеләр;

3) муниципаль учреждениеләр-мәйданнар, урамнар, юллар, скверлар, бульварлар, һәйкәлләр, су объектлары, пляжлар биләгән гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата.

Салым ташламасын билгеләү :

2 статьяның 6 пункты (0,15%) белән Татарстан Республикасы бюджетларыннан һәм муниципаль берәмлек бюджетыннан финанслана торган автоном, бюджет учреждениеләренең, хакимият һәм идарә органнарының җир кишәрлекләренә карата билгеләнгән ставканың 1/10 күләмендә;

**4. Статья. Хисап чоры .**

Салым түләүче оешмалар һәм шәхси эшмәкәрләр булган физик затлар өчен хисап чоры дип календарь елның беренче кварталы, икенче кварталы, өченче кварталы танысла дип билгеләргә.

**5 Статья. Салым түләү тәртибе һәм сроклары**

Физик затлар булган һәм салым түләүче салым түләүчеләр өчен салым түләү узган салым чорыннан соң килүче елның 2 ноябреннән дә соңга калмыйча башкарыла.

Салым түләү турында салым белдерүе салым түләүчегә Россия Федерациясе Салым кодексының 52 статьясында билгеләнгән сроктан да соңга калмыйча тапшырыла.

Салым түләүче-оешмалар яисә шәхси эшмәкәрләр булган физик затлар өчен салым түләү беренче, икенче һәм өченче квартал узганнан соң җир кишәрлегенең кадастр бәясенең процент өлешенең тиешле салым ставкасы күләмендә, узган хисап чорыннан соң килгән икенче айның 10 числосыннан да соңга калмыйча, аванс түләүләре белән башкарыла.

**6 Статья. Салым түләүчеләрнең салым салу базасын киметү хокукын раслый торган документларны тапшыру тәртибе һәм сроклары.**

Россия Федерациясе Салым Кодексының 31 бүлеге нигезендә салым базасын киметү хокукын раслый торган документлар салым салу объекты дип танысла торган җир кишәрлегенең урнашу урыны буенча салым органына тапшырыла:

1) шәхси эшмәкәр булган физик затлар тарафыннан салым буенча салым декларациясе тапшыру өчен билгеләнгән срокларда.

2) салым түләүчеләр – шәхси эшмәкәр булмаган физик затлар-узган салым чорыннан соң килә торган елның 1 февраленә кадәр.

Салым чоры тәмамланганчы салым түләүчеләр тарафыннан салым базасын киметүгә хокук барлыкка килгән (туктатылган) очракта, әлеге хокук барлыкка килүне (туктатылуны) раслаучы документлар, ул барлыкка килгән (туктатылган) көннән алып 15 көн эчендә бирелә.

**Статья 7. Вступление в силу настоящего Решения.**

Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советы түбәндәге карарларын үз көчен югалткан дип санарга:

«Җир салымы турында» 2010 ел, 27 октябрь, 6 нчы карары

2011 ел, 15 апрель № 26 «Татарстан Республикасы Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 27.10.2010 ел, № 6 «Җир салымы турында» карарына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында.

01.03.2012 елның, № 38 «ТР Чирмешән муниципаль районы Күтәмә авыл җирлеге Советының 15.04.2011 ел, № 26 “Җир салымы турында» карары.

Әлеге карар 2014 елның 1 гыйнварыннан, «Безнең Чирмешән» - «Наш Черемшан " район газетасында рәсми басылып чыкканнан соң бер ай узгач барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла».

Башлык, Күтәмә авыл җирлеге Советы Рәисе Аброськина А.Н.